**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч торак пунктында гражданнар җыены карары**

2025 елның 29 ноябре № 3

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2025 елның 29 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч торак пункты узган территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2026 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кирлегәч авылы юлларын кардан чистарту);

2) ремонт, киртәләр кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Кирлегәч авылының Тукай урамындагы зират территориясендә үлән, коры-сары чабу һәм куакларны кисү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 299 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 155 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 155 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч торак пункты узган территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кирлегәч авылы юлларын кардан чистарту);

2) ремонт, киртәләр кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Кирлегәч авылының Тукай урамындагы зират территориясендә үлән, коры-сары чабу һәм куакларны кисү) соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Кирлегәч авылы, Совет урамы, 33А йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Кирлегәч авыл җирлеге башлыгы С.Р.Сәлахова